ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 184 от «03» 06 2026 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү Тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 281.1 статьясы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибен расларга. (Карарга кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының Интернет челтәрендәге http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Җитәкче А.М. Ефимов

0000013519

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
03 06 2026ел, №
карары белән расланды 184

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керешүче зат һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муни-ципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат (алга таба - муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат) һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе (алга таба-муниципаль учреждение җитәкчесе) тарафыннан үз иренең яки хатынының, һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү кагыйдәләрен билгели (алга таба - керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр).

2. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат эшкә кергәндә түбәндәгеләрне тапшыра:

2.1. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар бирү елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан (элекке эш урыны буенча керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган үз керемнәре турында белешмәләр, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керешү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) милек хокукындагы мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр.

2.2. Үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре (элекке эш урынындагы керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керү өчен документлар муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат тарафыннан бирелгән елга кадәрге календарь ел өчен белешмәләр, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру алдындагы айның беренче числосына милек хокукындагы мөлкәт һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (хисап датасына).

3. «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында белешмәләр бирү өчен нигезләр барлыкка килгән очракта, муниципаль учреждение

җитәкчесе түбәндәге елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча түбәндәгеләрне тапшыра:

3.1. «Дәүләт вәкаләтләрен биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының (хисап чорын кертеп) туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон нигезендә чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен төзелгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр алынган керемнәре турындагы белешмәләр (хезмәт платасын, пенсияләрен, пособиеләрен, башка түләүләрне дә кертеп), шулай ук хисап чорындагы хәлләр буенча мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

3.2. «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының (хезмәт хакын, пенсияләрен, пособиеләрен, башка түләүләрне кертеп) туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 03декабрендәге № 230-ФЗ Федераль закон нигезендә чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 31 декабренә кадәр үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында (хисап чоры), барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп), шулай ук аларның милек хокукындагы мөлкәт турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне.

.4. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе Президентының рәсми сайтында урнаштырылган «Белешмәләр БК» махсус программа тәэмин ителешен файдаланып тутырылган белешмә формасы буенча тапшырыла.

5. Әлеге Тәртипнең 2 һәм 3 пунктларында каралган белешмәләр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетына (Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар эше һәм муниципаль хезмәт секторына) һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының аларның җитәкчеләренә муниципаль учреждение җитәкчесен вазыйфага билгеләү һәм вазыйфасыннан азат итү вәкаләтләре бирелгән тармак органнарына тапшырыла

6. Әгәр муниципаль учреждение җитәкчесе керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында үзе тапшырган белешмәләрдә нинди дә булса белешмәләрнең чагылдырылмавын яисә тулысынча чагылдырылмавын йә хаталар булуын ачыкласа, ул төгәлләштерелгән белешмәләрне әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә тапшырырга хокуклы.

7. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында үзе тапшырган белешмәләрдә нинди дә булса белешмәләр чагылдырылмаган яисә тулысынча чагылдырылмаган йә хаталар булган очракта, ул белешмәләр тапшырылган көннән алып бер ай эчендә әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

8. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат һәм муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү гамәлдәге законнарда билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

9. Әлеге Тәртип нигезендә тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр конфиденциаль характердагы белешмәләр булып торалар, федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләргә кертелмәгәнме.

10. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына кергәндә затның яллаучы (хезмәткәр) вәкиленә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук үз иренең (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмавы, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган белешмәләр тапшыруы, йә белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү күрсәтелгән затны муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Муниципаль учреждение җитәкчесенең әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган бурычын үтәмәве аны билгән вазыйфасыннан азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.